КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 21 июнь г.Казань № 451

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 апрель, 281 нче; 2018 ел, 14 июнь, 481 нче; 2018 ел, 17 октябрь, 940 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1320 нче; 2021 ел, 17 ноябрь, 1087 нче; 2021 ел, 13 декабрь, 1222 нче; 2022 ел, 17 сентябрь, 1015 нче; 2024 ел, 30 апрель, 290 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына, беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Әлеге нормативлар җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасар-ларының, аудиторларының, соңгы өч хисап финанс елының ике елы дәвамында бюджетларында Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджет-ларыннан дотацияләр өлеше, муниципаль район һәм җирлекләр тарафыннан төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга бирелә торган субвенцияләрдән һәм башка бюджетара трансфертлардан тыш, (җирле бюджетларга иң яхшы күрсәткечләргә, шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм (яки) аларга ирешүне бүләкләү һәм (яки) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең иң яхшы тәҗрибәләре өчен бүләкләү максатларында бирелгән дотацияләрне һәм (яки) өстәмә түләүләр нормативлары белән алыштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләү күләменнән (дотациянең исәп-хисап күләме өлешеннән) артмаган күләмдә өстәмә түләүләр нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча) җирле бюджет керемнәренең биш процентыннан артык булган Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары күләмен билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин